| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Буа шәһәре

16.02.2022 ел № 8

Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны
һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү
һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп
кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру тәмамлану
турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан
рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 16 августтагы 59 номерлы «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру тәмамлану турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру тәмамлану турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.5 пункты:

2.5.1 пунктчасына түбәндәге редакциядә 11 абзац өстәргә:

«11) күпфатирлы йорттагы биналарны яңадан урнаштыру һәм (яисә) яңадан планлаштыру эшләрен газ бүлүче оешма белән килештерүне раслый торган документ.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Я. Галәветдинов